ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.08.2021 ел Баулы шәһәре №165

2021-2022 уку елында Баулы муниципаль
районы мәгариф учреждениеләре
укучыларын тукландыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 нчы маддәсе, «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль мәгариф оешмаларында (күрсәтелгән мәгариф учреждениеләрендә шундый укучылар санының 100 процентын колачлауны тәэмин итүче) башлангыч гомуми белем алучыларның түләүсез кайнар туклануын оештыру буенча чаралар исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 июлендәге 588 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20219 елның 28 августындагы 724 номерлы «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» карары кушымтасына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 24 августындагы 728 номерлы карары нигезендә, муниципаль мәгариф учреждениеләре укучыларын тулысынча тукландыруны тәэмин итү, СанПиН 2.4.5.2409-08 «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру» турындагы таләпләрен үтәү максатларында, шулай ук аерым категория укучыларга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУны Баулы муниципаль районы бюджетыннан район һәм шәһәр мәгариф учреждениеләрендә ташламалы кайнар туклануны оештыруны гамәлгә ашыручы предприятиеләргә субвенцияләр бирү буенча Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

2. 2021 елның 1 сентябреннән Баулы муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениесендә уку чорында бер укучыга исәпләнгән көнлек кайнар туклану бәясенең күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

бюджет исәбеннән:

- шәһәр һәм авыл мәгариф учреждениеләренең 1-4 класс укучылары өчен 53 сум 41 тиен;

- 5-11 сыйныф укучылары өчен 8 сум 00 тиен;

ата-ана кертемнәре исәбеннән:

- 5-11 сыйныф укучылары өчен: шәһәрдә иртәнге аш - 15 сум, төшке аш - 43 сум; авылда иртәнге аш - 15 сум, төшке аш - 33 сум.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Д.З. Ганиевага Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (ЕГИССО) куллану юлы белән социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров